КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 июнь г.Казань № 602

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 май, 356 нчы; 2016 ел, 16 июнь, 408 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2018 ел, 14 март, 152 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1153 нче, 2020 ел, 22 июль, 617 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 28 статьясы, «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2022 елның 29 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт теркәвенең, рәсми бастырып чыгаруның һәм үз көченә керүнең аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Президентының "Республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу, рәсми рәвештә бастырып чыгару,аларның үз көченә керүе, Татарстан Республикасында Россия Федерациясе хокукый мәйданы бердәмлеген тәэмин итүнең аерым мәсьәләләре һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларын үз көчен югалткан дип тану турында" 2017 елның

28 сентябрендәге ПУ-861 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрендә:

1.5 пунктта «һәм дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча административ регламентларны» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6 пунктта «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына факттагы йогынтыны бәяләү һәм экспертиза ясау тәртибе турында» сүзләрен «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Дәүләт теркәвенә алынырга тиешле норматив хокукый актлар республика башкарма хакимияте органы җитәкчесе кул куйган һәм тиешле республика башкарма хакимият органында теркәлгән көннән алып өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелә. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булган норматив хокукый актлардан, конфиденциаль характердагы белешмәләрдән, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә игълан ителергә тиеш булмаган башка белешмәләрдән тыш, электрон образ рәвешендә Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы ярдәмендә җибәрелә. Электрон образ, норматив хокукый актка кул куелып теркәүгә алынганнан соң, аның кәгазь чыганагын сканерлау юлы белән булдырыла.

Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне, конфиденциаль характердагы белешмәләрне, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә игълан ителергә тиеш булмаган башка белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар кәгазь саклагычта чын нөсхәдә җибәрелә.»;

3.1 пунктта «дәүләт сере яисә конфиденциаль характердагы белешмәләр» сүзләрен «дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр, конфиденциаль характердагы белешмәләр, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә игълан ителергә тиеш булмаган башка белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару булып аларның тулы текстларын «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасы законнары җыелмасы» журналында беренче тапкыр бастыру яки Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) яки Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталында (www.pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару) санала. Шулай ук хокукый мәгълүматның интегральләшкән тулы текстлы банкына (хокукый

мәгълүматның эталон банкы) кертелгән норматив хокукый актлар текстлары рәсми булып тора.»;

3.4 пунктта:

икенче абзацта «йә норматив хокукый актны Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталында урнаштыруны тәэмин итә» (www.pravo.gov.ru)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип таныргa;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә, әгәр әлеге актлар үз көченә керүнең башка тәртибе каралмаган булса, .

Кеше һәм граждан хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы норматив хокукый актлар аларны рәсми бастырып чыгарган көннән соң 10 көннән дә иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Норматив хокукый актны рәсми бастырып чыгарганда аның исеме, вазыйфаи заты, аны имзалаган вазыйфаи зат, аның бастырылу урыны һәм датасы, теркәү номеры күрсәтелә.

Норматив хокукый актны бастырып чыгарганда һәм таратканда аның дәүләт теркәвенә алу датасын һәм Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары дәүләт реестрындагы номерын күрсәтү мәҗбүри булып тора.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе тәртибе турында» 2002 ел, 5 сентябрь, 524 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 18 апрель, 212 нче; 2015 ел,  29 сентябрь, 722 нче; 2016 ел, 16 июнь, 408 нче; 2018 ел, 27 ноябрь, 1062 нче, 2019 ел, 25 июль, 621 нче, 2021 ел, 01 октябрь, 943 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулага «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2022 елның 29 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары аларны бастырып чыгарган көннән соң 10 көн эчендә мәҗбүри рәсми басылып чыгарга тиеш, күрсәтелгән карарларның яисә аерым нигезләмәләренең дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр, конфиденциаль характердагы белешмәләр, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә  игълан ителергә тиеш булмаган башка белешмәләрдән тыш»;

2 пунктның беренче абзацында «, шулай ук кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр, конфиденциаль характердагы белешмәләр, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә хәбәр ителергә тиешле башка белешмәләр булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары аларга имза салынган көннән үз көченә керә.»;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин